РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**МУСЛЮМОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУСЛЮМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**МӨСЛИМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

*№ 10* *« 24 » декабрь 2020 г*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Мөслим районы Прокуроры протестын карау нәтиҗәләре буенча, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мөслим авыл җирлеге Башкарма комитетының «Адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 3 февралендәге 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.1 пунктта «һәм адресация объектлары исемлеге» сүзләрен өстәргә;

- 1.5 пункттагы «адресация объектының идентификация элементлары» – «җир кишәрлекләре номерлары, башка адресация объектларының типлары һәм номерлары» редакциясендә бәян итәргә;

- 1.5 пунктка «адресация объекты булып торалар:

- бина (капиталь булмаган төзелештән тыш төзелеш ), шул исәптән төзелеш тәмамланмаган бина;

- корылма (капиталь булмаган корылмадан һәм линия объектыннан тыш) шул исәптән төзелеп бетмәгән төзелеш;

- җир кишәрлеге (торак пунктларның җирләренә карамаган һәм аларга капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен билгеләнмәгән җир кишәрлегеннән тыш);

- капиталь төзелеш объектының бер өлеше булган бина» сүзләрен өстәргә.

- машина урыны (капиталь булмаган бинаның яисә корылманың бер өлеше булган машина урыныннан тыш).

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында muslumovo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә адресларны бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.З.Сахбетдинов**